**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 29 декабрендәге 4709 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 1 июлендәге 2004 номерлы «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан 2025 елда эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 19 ноябрендәге 10406 номерлы «Казан шәһәре муниципаль учреждениеләренә карата муниципаль бирем формалаштыру һәм муниципаль биремне үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында»гы, 2021 елның 3 ноябрендәге 2906 номерлы «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарлары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 1 июлендәге 2004 номерлы «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан 2025 елда эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) норматив чыгымнарны раслау турында»гы карарына (алга таба – 2025 елның 1 июлендәге 2004 номерлы карары) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарның кушымтасын 2025 елның 1 июлендәге 2004 номерлы карарына кушымта дип санарга.

2. Кертелә торган үзгәрешләр 2025 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 29 декабрендәге
4709 номерлы карарына
кушымта

**«Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) 2025 елга норматив чыгымнар**

| № т/б | Муниципаль эш (хезмәт) исеме | Муниципаль эш (хезмәт) эчтәлеге | Норматив чыгымнар (елына сумнарда) |
|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** |
| 1 | Территорияләрне планлаштыру документларын әзерләү | Территорияне планлаштыру проектын әзерләү | 14 135 528,88 |
| | | Территорияне ызанлау проектын әзерләү | 4 501 551,67 |
| | | Инженерлык-геодезик тикшеренүләр» | 7 120 523,49 |
| 2 | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү өчен документлар әзерләү | Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү өчен документлар әзерләү | 14 163 151,23 |
| 3 | Кадастр эшчәнлеген башкару | Дәүләт кадастр исәбен башкару өчен кирәкле белешмәләр булган документларны әзерләүдә күчемсез милеккә карата эшләр башкару | 18 850 950,31 |
| 4 | Эшчәнлекне административ яктан тәэмин итү | Проектлар белән идарә итү | 100 836 898,41 |
| | | Анализ үткәрү | 7 143 538,83 |
| | | Мониторинг үткәрү | 13 880 308,48 |
| 5 | Архитектура-төзелеш буенча проектлаштыруны башкару | Күчемсез милек объектларының проект-смета документларын эшләү | 85 598 451,70 |